КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 март г.Казань № 206

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты структурасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 13 сентябрь, 667 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты структурасын камилләштерү, аның эшчәнлеге эффективлыгын яхшырту максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты структурасына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 13 сентябрь, 667 нче карарына, 1 пунктның икенче абзацындагы «һәм Ситуацион үзәк эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге» сүзләрен «, Ситуацион үзәк эшчәнлеген тәэмин итү секторы һәм режимлы эш секторы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка ике атна эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппаратының штат расписаниесенә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр кертергә.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин